

Кыңгырау чылтырый һәм тына,
Дәрескә чакыра ул безне.
Яңалык белергә, ачышлар ясарга
Әзерме биредә һәрберсе?

.

# Саннарны тезәргә ярдәм итегез!



# Сез беләсезме?




Илсур, Марат һәм Динә
Өч песнәккә җим сибә.
Килде тагын бер песнәк,
Ничә песнәк булды, әйт?



**3 + 1 = 4**

Дүрт бәбкәсен ияртеп
Суда йөзә бер үрдәк.
Әйтеп бирегез тизрәк,
Барысы ничә үрдәк?



$4 + 1 = 5$


# Алу гамәле

**кимүче киметүче аерма**

$$5 - 1 = 4$$



# Математик язма төзегез:





# Кагыйдә:



**Бирелгән саннан 1не алу нәтиҗәсе булып аның алдыннан килгән сан тора**

# Дәрес темасы: 1 санын алу

**Дәреснең максаты:** Киметүче 1 булганда аерманы табарга өйрәнү

1. Дәреслекнең 4 нче битендә киметүчеләре 1 булган аермаларны табарга һәм дәфтәргә язарга.
2. Бу аермаларның кыйммәтен табарга, астына сызарга.
3. Дәреслектәге рәсем белән парлап эшләргә.
4. Математикадан эш дәфтәрендә 18 нче биттәге №1, №2 биремнәрне мөстәкыйль эшләргә
5. Үзбәя.



## 1нче бирем

1 Биремне укы.

2.Уйла.

3.Аермаларны әйт.

4.Дәфтәргә аермаларны биремдәгечә яз.

5. Аерманың кыйммәтен тап.

6. Нәтиҗә яса.

## 2 нче бирем

1.Рәсемне кара.
2.Биремне ничек башкарырга икәнен күршең белән киңәшләш.
3.Математик язма төзе.
4. Сорауга җавап бир.




**Мөстәкыйль эш дәфтәрдәге №1, №2 биремнәр**

1.Сез нинди тема өйрәндегез?



2. Сез нәрсә белергә теләгән идегез?

3. Нинди кагыйдәне истә калдырдыгыз?



Сез бик тырышып эшләдегез.
Барыгыз да булдырдыгыз!
Рәхмәт!